ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2022 с. Муслюмово № 543

**Социаль түләү күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы буенча 2022 елның 4 кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак - коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Дәүләт программасының «2014-2019 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 14 гыйнварындагы 2 нче карары белән расланган «2021 - 2026 елларга Мөслим муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен 2022 елның 4нче кварталында торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясен түбәндәгечә расларга:

- Мөслим авылында 1 кв. м – 25093сум.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Ф. Салихҗанов